КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 29 апрель г.Казань № 347

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2020 елга Татарстан Республикасы дәүләт театр-тамаша мәдәният учреждениеләренең норматив чыгымнарын раслау турында» 2019 ел, 17 сентябрь, 842 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2020 елга Татарстан Республикасы дәүләт театр-тамаша мәдәният учреждениеләренең норматив чыгымнарын раслау турында» 2019 ел, 17 сентябрь, 842 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган 2020 елга Татарстан Республикасы дәүләт театр-тамаша мәдәният учреждениеләрендә спектакльләр (театраль куелышлар) күрсәтү (күрсәтүне оештыру) буенча дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә норматив чыгымнарның һәм күләмнәрнең 2 пунктында «549,42» һәм «755,69» саннарын «618,39» һәм «832,97» саннары белән алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган 2020 елга Татарстан Республикасы дәүләт театр-тамаша мәдәният учреждениеләрендә концерт программалары күрсәтү (күрсәтүне оештыру) буенча дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә норматив чыгымнарның һәм күләмнәрнең 1 пунктында «1 235,81» саннарын «1 255,54» саннарына алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган 2020 елга Татарстан Республикасы дәүләт театр-тамаша мәдәният учреждениеләрендә спектакльләр әзерләү буенча эш башкаруга норматив чыгымнарның 2 пунктында «5 799,4» һәм «411,4» саннарын «6 527,4» һәм «453,5» саннарына алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган 2020 елга Татарстан Республикасы дәүләт театр-тамаша мәдәният учреждениеләрендә концертлар һәм концерт программалары әзерләү буенча эш башкаруга норматив чыгымнарның 1 пунктында «3 652,5» саннарын «3 710,7» саннарына алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган 2020 елга Татарстан Республикасы дәүләт театр-тамаша мәдәният учреждениеләрендә спектакльләр күрсәтүне оештыру буенча эш башкаруга норматив чыгымнарның 2 пунктында «34 559,5» саннарын «35 642,5» саннарына алмаштырырга.

2. Бу карарның гамәлдә булуы 2020 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин